Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы өченче чакырылышының
егерме бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

2019 елның 25 апреле № 190

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 24 июлендә кабул ителгән 155 номерлы «2018-2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2011 елның 6 октябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәтне аукционда сату турындагы нигезләмәгә таянып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 24 июлендәге 155 номерлы «2018-2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) турында» гы карарына кушымтаның 2 бүлегенә (2018 елның 24 октябрендәге 168 номерлы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланган үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент белән хезмәттәшлек итү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
советы утырышы
карарына кушымта
2019 елның 25 апреле, № 190

## 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

| № п/п | Урнашу урыны | Милек исеме | Мәйданы, кв.м. | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Белкино авылы | Административ бина, билгеләнеше: торак булмаган бина кадастр номеры: 16:33:01 01 01:248 (җир кишәрлеге кадастр номеры: 16:33:010101:105) | 169,8 | 2-3 квартал 2019 ел |
| 2 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле авылы, Хәйруллин ур., 38 | Котельный билгеләнеше: торак булмаган бина кадастр номеры: 16:33:170107:153 (җир кишәрлеге кадастр номеры 16:33:170107:152) | 136 | 2-3 квартал 2019 ел |